**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлеге Иске Иглай торак пунктында гражданнар җыены**
**КАРАРЫ**

«21» ноябрь 2023 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Яңа Иглай авыл җирлеге Иске Иглай торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ**:**

Яңа Иглай авыл җирлеге Иске Иглай торак территориясендә яшәүче һәр балигъ булган кешедән, 1 гр инвалидларыннан тыш, балачактан инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, СВОда катнашучылардан кала 2024 елда 2000 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Иске Иглай торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту»;

- Иске Иглай авылы территориясен төзекләндерү һәм карап тоту өчен товарлар (эшләр, хезмәтләр) сатып алу.

Суүткәргеч төзү, халыкны эчәр су белән тәэмин итү өчен җыелган 2022 елда гражданнарның үзара салым акчаларының калдыгын 80000 (сиксән мең) сум 00 тиен һәм 321411 (өч йөз егерме бер мең дүрт йөз унбер) сум 05 тиен күләмендә республика акчаларын су белән тәэмин итү чыганакларын норматив таләпләрне тәэмин итү буенча эшләр башкаруга файдаланырга.

Халык җыенында рәислек итүче: И.Х. Хәнәфиев

Яңа Иглай авыл җирлеге башлыгы

вазыйфаларын башкаручы И.Х. Хәнәфиев